| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**12.02.2016** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 307** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнварындагы 124 номерлы “Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында”гы карарына 4 нче кушымтаны гамәлдән чыгару хакында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнварындагы 124 номерлы «Зеленодольскк муниципаль районы физик культура һәм спорт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында» карарын «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы Федераль законга туры китерү максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнварындагы 124 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында»гы карарына 4 нче кушымтаны гамәлдән чыгарырга.
2. МБМУ ӨББ “Бригантина” “6 нчы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе” җитәкчесенә 2016 елның 1 мартыннан да соңга калмыйча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы Федераль закон нигезендә түләүле хезмәтләр күрсәтүгә хезмәтләр исемлеген һәм тарифларны раслауга тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Хәлилова Л. Ш. йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин